КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1519

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими яшәү урыныннан киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 12 гыйнвар, 3 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими яшәү урыныннан киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 12 гыйнвар, 3 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 22 май, 624 нче; 2023 ел, 4 июль, 790 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «массакүләм» сүзен төшереп калдырырга;

преамбулада «башка территорияләргә ашыгыч массакүләм рәвештә» сүзләрен «Россия Федерациясенең башка территорияләренә ашыгыч рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «массакүләм» сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктта «массакүләм» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Даими яшәү урыныннан киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибендә:

исемендә «массакүләм» сүзен төшереп калдырырга;

1.1 пунктта «башка территорияләргә ашыгыч массакүләм рәвештә» сүзләрен «Россия Федерациясенең башка территорияләренә ашыгыч рәвештә» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта:

беренче абзацта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга, «башка территорияләргә ашыгыч массакүләм рәвештә» сүзләрен «Россия Федерациясенең башка территорияләренә ашыгыч рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «гражданнар» сүзе алдына «2022 елның 24 февраленнән соң» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2022 елның 24 февраленә карата гражданнар Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән;

14 яшькә җиткән гражданның – Россия Федерациясе гражданы паспорты була, ә 14 яшькә кадәрге балага карата – бала туу турында таныклык яисә баланың Россия Федерациясе гражданлыгы булуын раслый торган билге белән чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән бала туу турындагы таныклыкның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе, йә ата-ананың (ата-аналарның) паспортына (паспортларына) бала турындагы белешмәләр кертелгән ата-ананың (ата-аналарның) паспорты (паспортлары);

гражданнар элек Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән тәртиптә бирелә торган социаль түләүдән яисә субсидиядән файдаланып торак урыны белән тәэмин итү яисә торак шартларын яхшырту хокукын яисә гражданнарга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасы исәбеннән югалган торакны компенсацияләү максатларында бирелә торган социаль ярдәм чараларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашырмаган.»;

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Социаль түләү күләмен исәпләү, әлеге Тәртипнең 4.4 пунктында каралган социаль түләү күләмен исәпләү очракларыннан тыш, 2022 елның 13 октябренә карата гражданның гаилә хәленнән чыгып гамәлгә ашырыла.»;

2.2 пунктта:

икенче абзацның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданның, аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документлар (Россия Федерациясе гражданы паспорты, 14 яшькә кадәрге балалар өчен туу турында таныклык).»;

өченче абзацта «, ягъни: әлеге пунктның икенче абзацында каралган документ» һәм «йә Херсон шәһәрендә яисә Херсон өлкәсенең бер өлешендә күчемсез мөлкәткә

милек хокукын раслый торган документ, әгәр гражданның әлеге территорияләрдә аның даими яшәү фактын раслый торган документы булмаган очракта, гражданның Херсон шәһәрендә яисә Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү фактын раслый торган аңлатма язуын теркәп» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «документлар» сүзе алдына «Әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән,» сүзләрен өстәргә;

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык 2022 елның 24 февраленә карата гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәве турында, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча гражданнарның теркәлү исәбен гамәлгә ашыручы дәүләт органнарына, дәүләт хакимиятенең башка органнарына рәсми сораулар җибәрү юлы белән Херсон шәһәрендә яисә Херсон өлкәсенең бер өлешеннән гражданның даими яшәү урыныннан китүе турындагы белешмәләрне тикшерхне гамәлгә ашыра.»;

2.6 пунктның беренче абзацында «биш эш көне» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга, «15 эш көне» сүзләрен «20 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Министрлык, «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенең автоматлаштырылган мәгълүмат системасын (алга таба шул ук эзлеклелектә – Фонд, система) файдаланып, сертификатлар бирү турында карар кабул ителгән гражданнарның гаризаларын Фонд тарафыннан билгеләнгән тәртиптә эшкәртүне гамәлгә ашыра, әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар исемлеген (алга таба – исемлек) төзи һәм раслый. Гражданнар исемлеккә, гариза теркәлгән датадан чыгып, хронологик эзлеклелеккә кертелә.»;

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе гражданлыгы булу.»;

3.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданнарның әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килмәвен ачыклау.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.8^1$ һәм $3.8^2$ пунктлар өстәргә:

«$3.8^1$. Гражданнар тапшырган документлар, шулай ук Министрлыкның Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча гражданнарны теркәү исәбен башкаручы дәүләт органнарына, Херсон өлкәсенең вәкаләтле органына Херсон шәһәрендә яисә Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү урыныннан гражданның китүе турында, дәүләт хакимиятенең башка органнарына җибәрелгән рәсми сорауларга җаваплар нигезендә гражданнарның әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килмәве ачыкланган очракта, Министрлык мондый туры килмәү ачыкланган көннән алып биш эш көне эчендә социаль түләүне күчергәнгә кадәр аны гражданга бирү турында элек кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару турында карар кабул итә.

3.8[2]. Министрлык әлеге Тәртипнең 3.8[1] пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә гражданга кабул ителгән карар турында хәбәрнамә җибәрә.»;

3.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Граждан Министрлыкның гражданга социаль түләү бирүдән баш тарту турында карарын кабул итү өчен нигез булган сәбәпләр бетерелгәннән соң яисә Министрлыкның гражданга социаль түләү бирү турында элегрәк кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару турында карары кабул ителгәннән соң социаль түләү бирү турында гаризаны кабат бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин